| | |
|---|---|
| **ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 ел 1 ноябрь Кәүҗияк авылы № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авылы җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Кәүҗияк авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 15ноябренә 13 сәгать 30 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Кәүҗияк авылы җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Кәүҗияк авылында Сабантуй үткәрү территориясен койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм эш өчен түләү ;
- Кәүҗияк авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Кәүҗияк авылы мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу һәм эш өчен түләү ;
- газ 3512 махсуслаштырылган техникасын тоту(йөк үзбушаткычы): дизель ягулык- майлау, запас частьләр сатып алу;
- Кәүҗияк авылы территориясендә үлән чабу;
- Кәүҗияк авылы һәйкәлен тышлау буенча төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү ;

- Кәүҗияк авылында уләнчапкычы сатып алу;
- Кәүҗияк авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ә.Хөснетдинов